**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылында**
**гражданнарга үзара салым кертү турында**

14 ноябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Даныш авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1.Үзара салымны 2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә Даныш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар кала 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы КамаТамагы
муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлеге башлыгы Р.М. Вафин